**КАРАР**

**2022 елның 5 ноябре** **№1**

**Кукмара муниципаль районы Лельвиж авыл җирлегенең Лельвиж авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2022 елның 5 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

1. «Сез 2023 елда Кукмара муниципаль районының Лельвиж авыл җирлеге Лельвиж авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән» һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Лельвиж авылында Совет урамы, Яр буе урамы юлларына вак таш җәю; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;
- Лельвиж авылында Совет урамы, Яр буе урамындагы юлга вак таш җәеп, чокырларны төзекләндерү (вак таш сатып алу, ташу, җәю, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);
- Лельвиж авылының урам юл челтәрен карап тоту (юлларны кардан чистарту, территорияне җәй көне чабу; юл кырыен куаклардан һәм агачлардан чистарту; ягулык-майлау материаллары, агрегатлар, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
- Лельвиж авылында су белән тәэмин итү челтәрен ремонтлау;
- урам яктырту челтәрен карап тоту;
- мотопомпа сатып алу;
- Лельвиж авылында су башнясы урнаштыру өчен җир кишәрлеге рәсмиләштерү;
- спорт инвентаре сатып алу;
- Авыл көне бәйрәме үткәрү.

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыенының йомгаклау беркетмәсе нигезендә:

2022 елның 5 ноябренә торак пунктта яшәүче гражданнарның гомуми саны – 491 кеше.

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 387 кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны – 203.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен җыенда катнашкан 201 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашкан 2 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Лельвиж авыл җирлеге Лельвиж авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип таныраг.

2. Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны: «Сез 2023 елда Кукмара муниципаль районының Лельвиж авыл җирлеге Лельвиж авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Лельвиж авылында Совет урамы, Яр буе урамы юлларына вак таш җәю; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;
- Лельвиж авылында Совет урамы, Яр буе урамындагы юлга вак таш җәеп, чокырларны төзекләндерү (вак таш сатып алу, ташу, җәю, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);
- Лельвиж авылының урам юл челтәрен карап тоту (юлларны кардан чистарту, территорияне җәй көне чабу; юл кырыен куаклардан һәм агачлардан чистарту; ягулык-майлау материаллары, агрегатлар, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
- Лельвиж авылында су белән тәэмин итү челтәрен ремонтлау;
- урам яктырту челтәрен карап тоту;
- мотопомпа сатып алу;
- Лельвиж авылында су башнясы урнаштыру өчен җир кишәрлеге рәсмиләштерү;
- спорт инвентаре сатып алу;
- Авыл көне бәйрәме үткәрү.

«РИЗА» «КАРШЫ»

- кабул ителгән дип таныраг.

3. Гражданнар җыенның нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Лельвиж авыл җирлеге башлыгы Э.Ю. Игнатьева

ОГРН 1021607753254
ИНН 1623003890